Девушки носили шапочки сферической формы, мягкие белые калфачки, тканые или вязаные из белых нитей. Налобная и височная часть головы дополнительно украшалась налобным украшением из полоски кожи (ранние булгары) или ткани с нашитыми бляхами, бусинами, височными подвесками.



Головное женское покрывало. Шелк, золотное шитье. XVI – XVII вв.
Хатын-кызның баш япмасы. Ефәк, алтын җеп белән тегелгән. XVI – XVII йөзләр.
Woman’s silk head covering embroidered with gold thread. 16th-17th centuries.




Семейный портрет (Царица Сююмбека). Гравюра с утраченного оригинала XVIII в.

Гаилә портреты (Сөембикә ханбикә). XVIII йөзнең югалган оригиналыннан гравюра.

Family portrait (Queen Syuyumbikeh). Engraving – copy of non-extant original picture. 18th century.

Еще в древности обязательной частью убора замужних женщин было матерчатое покрывало. В этой традиции отразились древние языческие воззрения о магии волос, закрепленные позднее более совершенной религией – исламом, рекомендующим нивелировать очертания фигуры и прикрывать лицо. До универсального платка XIX века покрывала прошли долгий путь эволюции и разнообразия форм. Самое древнее покрывало "тастар" в виде узкого полотенца (точи холста)



Шейно-височное женское украшение. Серебро, позолота. Скань, инкрустация. Конец XVIII – начало XIX вв.

Хатын-кызның муен-чигә бизәнү әйбере. Көмеш, йөгертелгән алтын. Үреп-бөтереп, инкрустациялэп эшләнгән. XVIII йөз ахыры – XIX йөз башы.

Silvergilt neck and temple pendant; openwork filigree and inlaid work. Late 18th – early 19th centuries.




Способ ношения шейно-височной подвески в комплекте с шапочкой.

Муен-чигә асылмасын бүрек белән киеп йөрү рәвеше.

The way of wearing neck and temple pendant together with a cap.

требовало сложной драпировки и дополнительных тканевых частей, чтобы отвечать всем этим требованиям. Широкие привозные ткани, доступные знати, больше отвечали этим задачам и развили покрывала треугольной формы (өрпек) и прямоугольной большого размера. Эти покрывала закреплялись на голове узкими повязками, первоначально съемными, позднее – нашитыми, которые в силу яркости материала, иногда усиленного металлическими деталями, являлись дополнительным украшением. Сверху надевались шапочки сферической или конической формы. Усложненным их вариантом являлось “кашпау”, имеющее наушники, смыкающиеся под




Вид Казани. Гравюра О.Коха из книги Адама Олеария. 1630 г.

Казан күренеше. Адам Олеарий китабыннан О.Кох гравюрасы. 1630 ел.

View of Kazan. Engraving by O.Koch from the book by Adam Oleary. 1630.

подбородком, и наспинную часть в виде полосы ткани, закрывающую косы. В зависимости от социального положения эти уборы зашивались сверху чешуеобразно монетами, кораллами, жемчугом, бляшками.

В период позднего средневековья (XVI – XVIII вв.), в силу общей тенденции моды, верхняя часть таких головных уборов у знати сильно вытягивается в высоту, получает жесткую основу, тщательно декорируется и превращается в наиболее эффектную деталь женского костюма. Женские меховые шапки по форме приближались к мужским.



Девица Казанских татар. Художник А.Мартынов. 1808 г.

Казан татарлары кызы. Рәссам А.Мартынов. 1808 ел.

A Kazan Tatar Maiden. Painting by A.Martynov. 1808.



Казанская татарка XVIII в. Из альбома рисунков к сочинению И.Георги.

XVIII йөз казан-татар хатын-кызы. И.Георги әсәренә ясалган рәсемнәр альбомыннан.

A Kazan Tatar Woman of 18th century. Picture from the album to the book by J.Georgy.



Головное женское покрывало. Золотное шитье. Конец XVIII – начало XIX вв.
Хатын-кызның баш япмасы. Алтын җеп белән тегелгән. XVIII йөз ахыры – XIX йөз башы.
Woman's head covering embroidered with gold thread. Late 18th – early 19th century.

В одном стилевом решении с костюмом были и съемные украшения – нагрудные, накосные, украшения для рук. Для их изготовления использовалось, в основном, серебро, которое обрабатывалось в ранний период в технике чеканки, литья, зерни; в средневековье преобладала сканая техника. Декор украшений, наряду с геометрическим, растительным орнаментом, содержал и зооморфные мотивы. Сохранение их, хотя и в сильно стилизованном виде, объяснялось памятью предков.

В целом булгарско-татарский костюм раннего периода, оставаясь близким по покрою к одежде других народов Среднего Поволжья, отличался общим силуэтом и цветовой насыщенностью под влиянием ярких восточных тканей и эстетических идеалов мусульманского мира. Полихромия в одежде нарастала постепенно, утверждаясь в городах в среде феодально-торговой прослойки населения. Значительно позже она проникла и в отдаленные районы, в сельский быт.



Казанская татарка. Художник И.Б.Лопренс. 1768 г.

Казан-татар хатын-кызы. Рәссам И.Б.Лопренс. 1768 ел.

A Kazan Tatar Woman. Painting by J.B. Laprince. 1768.



Застежки женские на воротник. Серебро. Литье, штамповка, гравировка. XVII – XVIII вв.
Хатын-кызларның яка каптырмасы. Көмеш. Коеп, штамповкалап, граверлап эшләнгән. XVII – XVIII йөзләр.
Woman's collar buckles of cast silver with stamped and engraved decoration. 17th-18th centuries.



Браслет женский. Серебро. Гравировка. XII – XIII вв.

Хатын-кыз беләзеге. Көмеш. Граверлап эшләнгән. XII – XIII йөзләр.

Woman's bracelet of engraved silver. 12th-13th centuries.



Накосники. Бронза. Литье, гравировка. XVII – XVIII вв.

Чулпылар. Бронза. Коеп, граверлап эшләнгән. XVII – XVIII йөзләр.

Hair ornament of cast bronze with engraved decoration. 17th-18th centuries.



Браслет. Серебро, самоцветы. XVII – XVIII вв.

Беләзек. Көмеш, асылташлар. XVII – XVIII йөзләр.

Silver bracelet with semi-precious stones. 17th-18th centuries.

1 БҮЛЕК

VIII – XVIII ЙӨЗЛӘРДӘ БОЛГАР-ТАТАР КОСТЮМЫ

Татар милли костюмы тарихи үсешнең озын юлын үткән. Матди мәдәниятнең бер кисәге буларак, аңа гадидән катлаулыга таба камилләшү хас. Шулай да, чыганакларның җитмәве сәбәпле, аның үсешендәге борынгы һәм урта гасырлар чоры хакында гомуми рәвештә генә сөйләргә мөмкин. Идел Болгарстаны, Җучи Олысы (Алтын Урда) һәм Казан ханлыгының төп халкы кием-салымнар тегү өчен йортта эшләнгән материалларны: йон һәм җитен тукымаларны, постау, күн, йорт хайваннарының тиреләрен файдаланган. Ә кыргый җанварларның – кара-көрән төлке, сусар, кеш, кондыз – тиреләре бигрәк тә кыйммәт йөргән.

Аксөяк катлауларның парчадан, ефәк тукымалардан тегелгән киемнәр кию традицияләрен коры җир юлы белән Харәзем аша, су юлы белән Идел буйлап Каспий диңгезе аша Кытайдан, Урта Азиядән, Византиядән бу тукымаларны һәм киемнәрне кайтаручы сәүдәгәрләр дә хуплаган. Урта гасырларда шәрык тукымаларыннан тегелгән кием-салым ислемайлар, энҗе-мәрҗән һәм бизәнү әйберләре белән бергәттән бүләк итеп тә бирелгән, 922 елда Болгар иленә килгән Ибне Фазлан бу хакта үзенең китабында язып калдырган. Төрле җенестәге һәм яшьтәге кешеләрнең киемнәрендә киселешнең бер үк яки охшаш булу үзенчәлеге борынгы кием-салымның характерлы сыйфаты булган, ә аермалыклар икенчел билгеләр рәтендә торган.

Ир-ат һәм хатын-кыз киеменең нигезе булып күлмәк һәм киң атламлы ыштан торган. Алар өстеннән кыска җиңле яки җиңсез камзул (археологлар терминологиясендә "куртка") кигәннәр. Өс киеме булып озын чабулы, озын җиңле җиңелчә яки калын кафтан хезмәт иткән. Затлы өс киеме чапан турында мәгълүматлар бик күп сакланган.

Материалны азрак тоту һәм кием тегүне гадиләштерү омтылышы галимнәр шартлы рәвештә "туникасыман" дип атый торган киселешне тудырган. Ул бик борынгы заманнарда ук Шәрыкта барлыкка килгән; ялганма (төймәле) һәм җилбәгәй (төймәсез) киемнең төп типларын биргән, алар исә Евразиянең зур территориясендә генә түгел, ә Европада X – XI йөзләргә кадәр гамәлдә булган. Җилкәләрдә урталай бөкләнгән тукыма иңе төп калыпны тәшкил иткән, аның өске өлешенә туры җиңнәр утыртылган. Итәк аска таба киңәя барган ян җөйләре, кайбер очракта өстәмә чөйсыман ялгаулар исәбенә киңәйгән. Җиңнең ян җөйләре белән тоташкан урынына ертылудан саклау өчен канатсыман ялгау тегеп куелган. Эчке һәм җилбәгәй (төймәсез) киемнәрдә муен уемы озынча түгәрәксыман булган, тасма тукымадан эшләнгән кечкенә утыртма яка белән каймаланган, күкрәк уемы һәрвакыт уртага урнаштырылган.

Урта гасырларның башлангыч чорында туникасыман киемнәрнең күчмә тормышка яраклаштырылган төрләренең үзенчәлеге – итәкләренең шактый киңәюе. Хатын-кызларга ат өстендә йөрергә яки чүгәләп эшләргә туры килә торган күчмә тормыш хуҗалыгында мондый киселеш уңайлы булган. Өс киеме киеп йөрү рәвеше белән аерылып торган: кагыйдә буларак, каплатмасы (запах) сул якка ятып торган. Өс киемен бөтенләй каптырып кию традициясе киң таралган, бу каплатманың киң булмавы белән аңлатыла. Өске өлеш каптырылмаган очракта

CHAPTER 1

THE BULGAR TATAR COSTUME OF THE 8th - 18th CENTURIES

The national Tatar costume has advanced along a complicated path of historic development. As every element of material culture, it underwent the process of increasing perfection. However, for lack of information, the ancient and medieval periods of its development can be described only in general.

The major part of the population in the Volga Bulgaria, Juchi Ulus (Golden Horde) and Kazan Khanate used home-made materials for dress making, such as wool and flax textiles, leather, fur of domestic animals. Highly valued was the fur of wild animals: silver fox, marten, sable, and beaver.

Traditions of the elite to wear brocade and silk dress were supported by the merchants, who brought these textiles and cloths from China, Central Asia, Byzantine and Arabic countries by land routes through Khorezm or by water via the Caspian Sea and along the Volga river. In the medieval period, the clothes made of Oriental textiles were used as gifts together with aromatics, pearls and jewellery. This fact was mentioned in the book of Ibn-Fadlan who visited the country of Bulgars in 922.

The unity or similarity of dress styles irrespective of sex and age was characteristic of ancient dress, while differences were of much less importance.

Men's and women's clothing was based on shirts and wide-bottomed trousers. The short-sleeved or sleeveless "jacket" (in archaeologic terms) was worn over these items. The long-skirted and long-sleeved "caftan", light or warmed, served as outer clothes. Much more evidence is available regarding the "honorary" outer wear, the robe.

The want for most efficient use of material and simplification of sewing process resulted in a style arbitrarily called by scientists the "tunic-like cut". It originated from the Orient as early as the ancient times and created the basic types of wrap-around and pull-over dress, that was current at that time in the most part of the Eurasian territory, as well as in Europe up to the 10th and 11th centuries.

The cloth bent over the shoulders formed the basis to which straight sleeves were sewn in the upper part. The dress was of bell-bottomed type due to side parts expanded downwards or additional gores. The gussets were sewn in the joint of the sleeves with side parts protecting this place from being torn. Neckline of wrap-around and pull-over dress was given an oval shape and edged by textile strip to form a low-stand collar; the breast cutout was always located in the middle.

A specific feature of nomadic tunic-like dresses of the early medieval period is that skirts were significantly enlarged. For a nomadic life style, where women had to ride or work squat-like, this was quite a comfortable cut. Outer clothes differed in manner of its wearing: wrap-around as a rule to the left side. To wear it fastened up was a common tradition, which was due to its small wrap-around. However, if worn the dress unfastened in the upper part, the flaps were tucked to the sides forming lapels. Closer fitting and bigger wrap-over of the "caftan" were created by flap gores, sewed in between the back part and sides, or the back made of two parts with a seam running through the middle.

чабулар әйләндерелеп ике яклы кайтарма барлыкка китергәннәр. Төп өлеш һәм ян җөйләр арасына тегелгән итәк ялганмалары яки ике аерым тукыманы бер-берсенә арттактаның үзәге буенча беркетү кафтанның каплатмасы киң булуны, гәүдәгә ятып, сыланып торуны тәэмин иткән.

Ләкин, гомумән, урта гасырларның башлангыч чорында (VIII – X йөзләр) өс киеменең (кафтан, чапан) туникасыман өлгеле булуы һәммәсен охшаш итеп күрсәткән (X йөз башы авторы Ибне Рөстә нәкъ шулай кабул иткән), чөнки өс киемнәре бер үк дәрәҗәдә озын чабулы, җилкә өлешләрендә иркен, чабулары уртада каплатмалы, күкрәк һәм бил өлешләрендә каптырмалы булган.

Болгар-татар костюмы үсешендә урта гасырларның соңгы чоры өс киемендә җиңнәр кисүнең камилләшүе (уеп ясалган җиң төбе), арттактаны вертикаль җөйләр буенча билгә яткырып тегү, итәкләргә ян җөйләр буйлап ялганмалар өстәү, яканың камилләшүе җиң киңлеген төрлечә итү белән сыйфатлана. Болар кием төрләрен арттырган: билле җиңел казаки һәм аның калын төре – бишмәт, туннар; туры арттакталы, туры киселешле калган җиләннәр һәм чикмәннәр. Эчтән киелгән күлмәкнең киселеше элеккечә кала, озынлыгы үзгәрә. Ирләр күлмәге кыскара, тезләрне бераз гына каплап тора. Хатын-кыз күлмәге исә итәгенә киң булмаган бала итәк өстәлеп һәм бизәк өлешләре белән тулыланып озыная.

Борынгы заманнарда гаскәриләр көбә күлмәк белән, ә халыкның күпчелеге җылылык өчен өс киеме астыннан киеп йөргән кыска кием – камзул ("куртка") да акрынлап үзгәрә. Аның үсеше киселеше үзгәреп, җиңнәр юкка чыгу исәбенә торган саен гәүдәгә ныграк сылану юнәлешендә бара. Хатын-кыз камзулында өчпочмаклы кыекча күкрәк уемы барлыкка килә, ә сыланып торуы аны хатын-кыз сынына тагын да ныграк яраша торган итә.

Урта гасырлар чорындагы ир-ат костюмының мәҗбүри һәм зарури өлеше булып корал, букча һәм башка кирәкле әйберләр беркетелә торган, тукымадан яки күннән ясалган путалар саналган. Алар өстән тегеп куелган металл тәңкәләр белән бизәлгән, сырлы каптырмалары булган. Сәяктән, металлдан эшләнгән, коеп һәм челтәрләп-бөтереп ясалган төймәсәдәфләргә зур игътибар бирелгән. Модалы традицияләргә туры китереп, киемдә алар төрлечә урнаштырылганнар. Мисал өчен, XVI – XVIII йөзләрдә төймәләр рәттә 2–3 әр данә булып горизонталь рәвештә тегелгәннәр, баулар белән тоташтырылганнар, шуның белән бер генә төстәге тукымадан тегелгән костюмга өстәмә бизәлеш эффекты бирелгән. Каптырманың шундый төрен С.Герберштейн рәсемендә сурәтләнгән йомышлы татар кешесе киемендә күрергә була.

Татарларда иң борынгы аяк киеме булып күн аяк киемнәре санала: итекләр һәм үкчәсез җиңел туфлиләр, башмаклар һәм галошлар. Аларны тула оек дип аталган, калыбы белән итеккә охшаш постау яки киндер оеклар белән, кайвакыт аякчу – чолгаулар белән кигәннәр.

Борынгы болгарларда тире-күн һәм йон эшкәртү шулкадәр дәрәҗәдә камилләшкән ки, Европа һәм Азиянең күп халыкларында яхшы эшкәртелгән йомшак күнне, сәхтиянне "болгари", "болгари товар" дип атау гадәткә кергән. X – XIII йөз казылмаларында археологлар камил киселешле, басып төшерелгән бизәкле һәм хәтта сырлы металл бизәкләр ябыштырылган шундый аяк киемнәре табалар. Бизәлеш өчен шулай ук төрле төстәге күн өлге-аппликацияләр дә кулланылган.

Чәч йөртү хакында да әйтү кирәк. Ислам дине тарала барган саен ир-атларда чәчне бөтенләй кыру, сакал-мыекны китәрү, чит-читләрен кыру традициясе ныгып урнаша. Хатын-кызлар чәчләрен баш өстендә туры чәч юлы калдырып ике толымга үргәннәр, аларны аркага салып йөрткәннәр. Чәч йөртүнең бу төрләре баш киемнәренең һәм хатын-кызларда толымга тагыла торган бизәнү әйберләренең шуңа туры килгән формаларын барлыкка китергән.

X йөз башы болгарларында башны каплау гадәтен Ибне Фазлан да телгә ала. Баш киемнәре киездән, тиредән, йон һәм башка төрле тукымалардан яки аларның кушылмаларыннан эшләнгән. Чөйсыман дүрт кисәктән торган шар-конус рәвешле бүрек аеру-

CHAPTER 1
THE BULGAR TATAR COSTUME OF THE 8th - 18th CENTURIES

Viewed in the large, however, in the early medieval period (8th-10th centuries) the tunic-like cut of the upper garments ("caftan", "robe") brought them together visually (as it was described by Ibn Ruste - writer of the early 10th century), since they were similarly long-skirted, loose in shoulders, had the same wrap-over in the middle and fastenings on the breast and waist.

Late medieval period of Bulgar Tatar costume is characterised by modernisation of upper wear sleeve cut (curved armholes), back fitting along vertical seams, emergence of additional side godets, collar development, variations in sleeve width.

These resulted in the following dress versions: light fitted kazakin coat (man's knee-length coat with pleated skirt) and its warmer version - beshmet quilted coat, fur coats; still straight-backed jilyan and chekmen jackets with straight armholes. The cut of underwear shirt remained unchanged unlike its length. The man's shirt became shorter hardly covering the knees. The woman's shirt became longer while getting additional rather narrow flounce down the waist and increasing number of decorative elements.

Gradual changes also affected the short clothes - doublets ("jackets"). Ancient warriors wore these items under the chain armour, while the majority of the population - as a warm clothing under upper garments. Evolution of such clothes went towards more and more close clinging to the body owing to the cut and loss of sleeves. V-neck appeared in female version of the doublet, while, due to clinging, the garment became a better fit for woman's figure.

Used for weapons, bags, and other necessary accessories, waistbands made of cloth or leather were obligatory and indispensable components of men's costume in the medieval period. They were decorated by sewn-on metal plaques and had figured buckles. Great attention was also paid to buttons made of bone, metal-cast or open-work filigree ones. Their location on a garment was dependent of traditions and fashion. For instance, in the 16th-18th centuries the buttons were sewn on horizontally, 2-3 in a line, connected by laces, thus creating additional decorative effect for costumes made of monochrome textiles. This type of fastening may be seen from a Tatar of service class (persons bound by obligations of service to the Muscovite Russian State) in the picture by S. Herberstein.

The most ancient type of Tatar footwear was leather footwear - boots and shoes, slippers and golosh shoes. Tatars wore these items with canvas or linen tula oek stockings being similar in cut to the boots, or occasionally with ayakchu putties.

Ancient Bulgars have achieved such perfection in leather and wool processing, that many nations in Europe and Asia used to call well-dressed yuft and morocco leather "bulgari" or "Bulgarian ware". In excavations of the 10th-13th centuries, archaelogists have found this perfectly cut footwear, decorated with imprints and even with figured metal onlay plaques. Embroidery and leather appliques of different colours were also used for decoration.

The Bulgars have adapted from their Finno-Ugric neighbours light bast footwear - lapti sandals, which they wore in the same manner with tula oek stockings during agricultural work. The number of footwear articles was also replenished by valenki felt boots.

Few words should be said about hairstyles. As Islam propagated, the men have practised a custom to shave heads, shaved off or trimmed beard and moustaches. The women did up their hair in two plaits with partings in the middle or wearing them loosely. Such hairstyles formed corresponding types of headdresses and woman's hair ornaments.

In the early 10th century, a tradition of Bulgars to cover head with a cap was mentioned by Ibn-Fadlan. Headdresses were fabricated of felt, fur, woollen or other textiles, or their combinations. Sphero-conical cap made from four wedge-shaped parts was the most prevalent type. The warriors wore this cap under the helmet - rounded with Bulgars, and more sharp in the upper part during the Kazan Khanate period. Winter

ча киң таралган төрләрдән була. Шундый сырган бүрекне гаскәриләр очлым (шлем) астыннан кигәннәр – болгарларда ул өсте түгәрәкләнгән рәвештә булса, Казан ханлыгы чорында өсте очланып тәмамлана. Кышкы бүрекләр тиредән тегелгән һәм шул ук калыпны кабатлаган, ләкин, кагыйдә буларак, тыштан тире белән кырпу тотылган. Аксөякләрнең баш киеме кыйммәтле тиреләрдән эшләнгән, модага карап өскә таба сузынкы яки басынкы тәбәнәк рәвешле булган. Бизәлешләре аларның сәнгатьчә нәфис өслүбенә ярашкан. Әүвәлге чорда бүрекләрнең тагын бер төре – зур кырлары булган ерыклы бүрекләр дә киелгән. Авыл халкы мохитендә киез эшләпәләр рәвешендә, ләкин инде ерыксыз хәлдә алар XIX йөзнең ахырына кадәр, "колакчын" дип аталган тире бүрекләр аерым очракларда XVIII йөзгә кадәр сакланган.

Хатын-кыз баш киемнәре төрле-төрле булган. Аларда яшь үзенчәлекләре һәм гаилә мөнәсәбәтләре, шулай ук киеп йөрүченең социаль халәте ачык чагылган. Кызлар түгәрәк калыплы бүрекләр, тукылган яки ак җепләрдән бәйләнгән йомшак ак калфакчыклар кигәннәр. Башның маңгай һәм чигә өлешләре өстәмә рәвештә күн тасмадан (әүвәлгерәк болгарлар) яки тәңкәләр, сәйләннәр, чигә алкалары беркетелгән тукымадан торган маңгай бизәкләре белән бизәлгән.

Борынгы заманнарда ук кияүдәге хатын-кызлар баш киеменең мәҗбүри өлеше тукымадан эшләнгән япма булган. Бу традициядә чәчләрнең сихере турында борынгы мәҗүси карашлар чагылыш тапкан. Соңрак бу карашлар буй-сын сызымталарын тигезләргә һәм йөзне капларга куша торган камил дин – ислам дине белән беркетелгән. XIX йөздәге универсаль яулыкка кадәр япмалар форма төрлелегенең һәм үсешнең озын юлын үткәннәр. Барлык бу таләпләргә җавап бирү өчен "тастар" дип аталган тар сөлге рәвешендәге иң борынгы япмага катлаулы киң бөрмәле материя һәм өстәмә тукыма кисәкләре кирәк булган. Читтән кайтарылган, аксөякләр генә сатып алырдай киң тукымалар бу таләпләргә күбрәк җавап биргәннәр, өчпочмаклы япмаларны (өрпәк) һәм зур үлчәмле турыпочмаклы япмаларны камилләштергәннәр. Бу япмалар тар бәйләвеч ярдәмендә башка беркетелгәннәр, ул бәйләвечләр башлангыч чорда алынма, соңрак тегеп куела торган булган, соңгылары тукыманың ачык төстә булуына бәйле рәвештә кайвакыт металл өлешләр белән тулыланып, өстәмә бизәнү әйбере булып хезмәт иткән. Япма өстеннән түгәрәк шарсыман яки конус рәвешле бүрек киелгән. Ияк астында тоташа торган колакчынлы һәм арка өлешендә толымнарны каплаучы тукымалы "кашпау" – шуларның катлауландырылган бер төре. Иясенең социаль халәтенә бәйле рәвештә, баш киемнәре өстенә балык тәңкәсе кебек итеп акчалар, энҗе-мәрҗәннәр, җиз тәңкәләр тегеп куелган.

Урта гасырларның соңгы чорында (XVI – XVIII йөзләр), моданың гомуми юнәлешенә бәйле хәлдә, аксөякләрнең мондый баш киемнәре өскә таба нык кына сузыла, каты нигезле итеп эшләнә, җентекләп бизәлә һәм хатын-кыз костюмының аеруча көчле тәэсир ясый торган өлешенә әверелә.

Алынма бизәнү әйберләре – күкрәккә, толымнарга, кулларга беркетелә яки киелә торган әйберләр дә костюм белән бер үк өслүбкә буйсындырылган була. Аларны ясау өчен нигездә көмеш кулланылган, ул әүвәлге чорда чүкеп нәкышьләү, кою юлы белән эшкәртелгән; вак шарчыклар рәвешендә бөртекләндерелгән һәм ябыштырып куелган; урта гасырларда бөтереп-үреп эшкәртү өстенлек алган. Геометрик орнаментлар, үсемлек орнаментлары белән беррәттән бизәкләрдә зооморф мотивлар да бар. Аларның нык өслүбләшкән хәлдә булса да сакланып калуы ата-бабалар истәлеге белән аңлатылган.

Гомумән алганда, әүвәлге чор болгар-татар костюмы өлгесе белән Урта Идел буенда яшәгән башка халыклар кием-салымына якын булган хәлдә, гомуми силуэты һәм ачык төстәге шәрык тукымалары, мөселман дөньясындагы эстетик омтылышлар тәэсирендә туган төсләр күплеге белән аерылып торган. Киемдәге күптөслелек шәһәрләрдә, халыкның феодаль-сәүдәгәр катлавы мохитендә ныгып, акрынлап көчәя барган. Шактый соңрак ул ерактагы төбәкләргә, авыл көнкүрешенә үтеп кергән.

caps made of fur were of similar shape, but as a rule, had outer fur trimming. Headdresses of the elite were fabricated of precious furs, while their body was alternately stretched or flattened in accordance with the fashion. Decoration followed corresponding artistic styles.

In the early period there was one more type of caps - wide-brimmed hats with slits. With rural population they were in use, already without slits, up to the end of the 19th century, fur hats (kolakchyn) - up to the 18th century.

Women's headdresses were much more diverse and more distinct in reflecting age and family relations, as well as social position of their bearers.

Maidens wore spheroidal caps, soft white kalfak headdresses, woven or knitted of white thread. Forehead and temples were additionally decorated with leather (early Bulgars) or cloth bands with plaques, beads, temple rings.

Even in ancient times the textile head covering was the part and parcel of married woman's headdress. This tradition originated as a result of ancient heathen views on the magic of hair, which were further developed by more perfect religion, Islam, that recommended to hide body lines and cover face. Prior to the universal headscarf of the 19th century, the head coverings have advanced the long path of evolution and diversification. The most ancient tastar covering in the shape of narrow towel (linen length) required complicated draping and additional parts of cloth to be adequate for all these needs. Imported wide fabrics available for the elite, answered these needs more thoroughly and contributed to emergence of three-cornered oerpek coverings and large rectangular coverings. These headdresses were fixed by initially removable and later sewn narrow fillets, which served as additional decorations due to bright textiles sometimes ornamented with metal pieces. Spherical or conical cap was put onto this covering. Kashpau headdress represented more complicated version of the same, having earflaps that connected under the chin, and back part formed stripe of cloth to cover plaits. Depending on social position, these headdresses were worked scaly from the top with coins, corals, pearls and plaques.


By virtue of general fashion trends in the late medieval period (16th-18th centuries), the upper part of such headdresses of the elite was significantly stretched upwards, obtained rigid base, was thoroughly decorated and thus became the most fancy component of woman's costume. Fur caps for women came close in shape to those for men.

Ornamentation - pectorals, hair ornaments, rings, and bracelets were of the same stylistic solution as that for the costume. For their manufacturing, silver was basically used, that was chased, cast, or granulated in the early period, while in the medieval period the filigree technique was prevalent. Along with geometric and foliate ornaments, decoration patterns also contained zoomorphic subjects. Conservation of these zoomorphs, though strongly stylized, was due to remembrance of ancestors.

As a whole, the Bulgar-Tatar costume of early period, while being close in cut to the dress of other Middle Volga peoples, differed in general silhouette and richness of colours under the influence of bright Oriental fabrics and aesthetic ideals of the Moslem world. Polychromy in dress was built up gradually, as it gained a foothold in the cities among feudal and merchant strata. Well after it penetrated into far away locations, into rural life.

2







КОСТЮМ
НАЧАЛА И СЕРЕДИНЫ XIX в.

Праздничный костюм зажиточной горожанки первой половины XIX в.

XIX йөзнең I яртысында бай шәһәр хатын-кызының бәйрәм костюмы.

Festive costume of a well-off woman in the first half of the 19th century.

Первая половина XIX в. – это время бурного развития татарского торгового капитала, нацеленного царским правительством на торговлю со Средней Азией, развитие промышленности, что сказалось и на эволюции одежды. Костюм этого времени наследует в целом стилевой ансамбль предыдущего периода (особенно XVIII в.), но некоторые его детали видоизменяются.

КОСТЮМ
НАЧАЛА И СЕРЕДИНЫ XIX в.

Мужская одежда состояла из белой рубашки туникообразного покроя с воротником-стойкой, шитой, в зависимости от имущественного состояния, из холста или тонкой полотняной материи. Праздничные рубахи горожан иногда шились с отложным воротником, украшенным вышивкой, но прямой грудной разрез сохранялся неукоснительно. В обычае было носить двое штанов: нижние ("штан") из светлой тонкой ткани и верхние ("чалбар") более темных тонов, чаще в полоску. Сверху одевали камзол ("камзул"), представляющий легкую домашнюю одежду. Настоящим же верхним платьем для выхода на улицу в теплое время года являлся приталенный казакин или прямоспинный джилян и чекмень ("җилән" и "чикмән"), чаще без подкладки. Камзолы, казакины и джиляны в этот период времени шили из ярких разноцветных шелковых, атласных, парчевых восточных тканей; а чекмени – из темных, однотонных, шерстяных.

Мужские штаны из холста и шелка.

Киндердән һәм ефәктән ир-ат ыштаннары.

Man's trousers made of linen and silk.





Мужская рубаха. Ситец.
Ир-ат күлмәге. Ситсы.
Man's shirt made of chintz.

Свадебная портянка с золотной тамбурной вышивкой.
Туйда киелгән алтын тамбур чигүле аяк чолгавы.
Wedding foot-binding chain-stitched with gold thread.

Камзол из парчи.
Парча камзул.
Doublet made of brocade.



Мужские тюбетейки. Бархат, позумент, золотное шитье. Середина XIX в. Конец XIX в.


Ир-ат түбәтәйләре. Бәрхет, укалы тасма (позумент), алтын җеп белән тегелгән. XIX йөз уртасы. XIX йөз ахыры.

Man's velvet skullcaps worked with gold thread; galloon trimming. Mid-19th - late 19th century.

Зимней одеждой являлись приталенный утепленный бишмет и шубы как облегающие фигуру, так и прямоспинные. Подпоясывали только зимнюю одежду для тепла.

Облегающая одежда выполнялась путем забора ткани на талии в вертикальные швы спинки и боков. Глубокий запа́х верхней одежды достигался дополнительными боковыми клиньями на подоле. Это придавало татарской одежде приталенный вид, в целом трапециевидный силуэт, что соответствовало и европейским тенденциям моды первой половины XIX в.

Головным убором, который мужчины носили постоянно, была тюбетейка ("такыя"). Она представляла собой полусферу или невысокий конус. Шили ее из ярких тканей с рисунком; однотонные же сплошь покрывали вышивкой и аппликацией позументной лентой. На тюбетейку надевали зимой меховую шапку также в форме полусферы. У лиц, занятых в торговле, начинают появляться шапки в форме невысокого цилиндра, из меха каракуля, с плоским верхом, но широкого распространения в этот период они не получили.



В XVIII веке такой формы шапки, отороченные более высоким мехом, встречались тоже редко, в основном, в среде служилых татар.

В женской одежде, как и в мужской, основными являлись рубашка и штаны. Далее шли: камзол, бишмет, шуба и джилян, того же покроя, как и мужские, с небольшими отличиями. Большей оригинальности достигла рубаха, превратившись из нательной одежды собственно в платье, хотя и носилась непременно с камзолом и сохранила туникообразный покрой. Это связано с патриархальным укладом быта, когда женщина большую часть времени проводила дома.

Уже к концу XVIII в. заканчивается замена белого холста для пошива женской рубахи на однотонный – крашеный или пестрядь. Этот процесс, продиктованный практичностью, у казанских татар завершается на столетие раньше, чем у других этнических и территориальных групп

Перстень-печатка. Серебро, позолота, самоцвет.

Мөһерле йөзек. Көмеш, йөгертелгән алтын, асылташ.

Silvergilt signet ring with a semi-precious stone.



Крой казакина, бешмета и приталенных шуб (вид спереди и сзади).

Казаки, бишмәт һәм билле тун киселеше (алдан һәм арттан күренеше).


The cut of kazakin coat, beshmet coat and fitted fur coats (front and rear view).




Верхняя мужская одежда – казакин. Шелк, бархат.
Ир-атларның өс киеме – казаки. Ефәк, бәрхет.
Man's outer wear – kazakin coat – of silk and velvet.

татар и финно-угорских народов. Толчком к этому послужили яркие восточные ткани, позднее и то, что к 1815 году Европа расстается с белым цветом для торжественных случаев, считая его непригодным, признаком бедности.

Окрашенные естественными красителями нити давали все оттенки приглушенно-красного цвета, цвета охры, светло-коричневого, зеленого, синего, желтого. При ткачестве их выполняли в виде розеток, полосок и клеток, подражая контрастной цветовой структуре восточных тканей и мануфактурных изделий. На таких ярких по тональности женских рубахах вышитый орнамент, располагавшийся ранее вдоль грудного разреза, на подоле, рукавах, и в древности имевший, кроме эстетического, и охранительный характер, стал незаметен. Он заменяется тканевой



Крой джиляна.
Җилән киселеше.
The cut of jilyan jacket.



Праздничные костюмы зажиточных горожан.

Шәһәр байларның бәйрәм костюмнары.

Festive costumes of well-off townspeople.



аппликацией на подоле и груди. Так возникает "изу" – закругленный нагрудник из полосок ткани и лент, обрамляющий грудной разрез и первоначально не являющийся съемным. Разноцветные полоски нагрудника объединяли контрастные цвета плечевой одежды и головного убора. Это акцентное значение "изу" позволяло варьировать детали костюма, для удобства его сделали съемным. Вышивка сохраняется только в отдельных случаях сверху подольного волана на цветных, но однотонных тканях.

Женский костюм с нагрудной тканевой аппликацией "изу" и перевязью "хэситэ".

Күкрәк өлешендә тукыма аппликацияле изүе һәм бәйләвеч хәситәсе булган хатын-кыз костюмы.

Woman's costume with izyu ruffle and khasiteh shoulder-belt.

Нагрудное съемное украшение – "изу". Шелк, бархат, позумент, самоцветы.

Күкрәк өлеше өчен алынмалы бизәк – "изү". Ефәк, бәрхет, укалы тасма, асылташлар.

Izyu ruffle with a galloon-trimmed silk and velvet base with semi-precious stones.





Женский камзол из золотной парчи.
Алтынлы парчадан тегелгән хатын-кыз камзулы.
Woman's doublet made of gold-thread brocade.

Так как рубаха никогда не носилась как самостоятельная деталь костюма, то на обшивку камзола перешли "охранительные" украшения белой рубашки. Тот же принцип соблюдался и для оформления женских и мужских джилянов.



Камзол с аппликацией золотной бахромой.
Алтын чук аппликацияле камзул.
Doublet with gold-thread fringe.

Калфаки. Трикотаж, бархат. Вышивка синелью, ушковая аппликация лентами.

Калфаклар. Трикотаж, бәрхет. Чук җебе белән чигелгән, тасмалардан элмәкле аппликация ясалган.

Kalfak knitted and velvet headdresses worked in chenille; silk appliqué.





С XVIII веком уходят в прошлое громоздкие и тяжелые шапки – “кашпау”, унизанные монетами. Молодые женщины и девушки носят мягкие калфачки, достаточно объемные для того, чтобы можно было их надеть на голову, закрыть волосы и шею сзади. В деревне их вяжут из тонких хлопчатобумажных нитей. Городские женщины для их пошива используют привозное тонкое трикотажное полотно или бархат. Ранние калфаки



Костюм молодой горожанки.
Шәһәрдә яшәүче яшь хатын-кыз костюмы.
Costume of a young townswoman.



украшались только вышивкой в налобной части, съемной или пришитой бахромой – повязкой “үкә-чәчәк”, височными кистями и кисточкой у завершения конуса. Позднее городские женщины, имевшие больше времени для занятия рукоделием, превратили калфачки в подлинные произведения искусства. Яркая аппликация из разноцветных лент по всей поверхности, вышивка пушистыми нитями синели, дополненная бусинками, жемчугом, металлическими нитями на полосатом фоне сделали калфак центральным декоративным элементом костюма.

Праздничный костюм зажиточной горожанки.

Шәһәрдә яшәүче бай хатын-кызның бәйрәм костюмы.

Festive costume of a well-off townswoman.

Декоративное оформление калфака. Ушковая аппликация шелком по бархату; вышивка бисером, золотной канителью, блестками.

Калфакның бизәлеше. Бәрхеткә ефәк белән элмәкле аппликация ясалган, сәйлән, алтын ука-җеп, ялтыравык тәңкәләр белән чигелгән.

Kalfak headdress decoration. Silk appliquй on velvet; worked with glass beads, gold bullion, paillettes.



КОСТЮМ
НАЧАЛА И СЕРЕДИНЫ XIX в.



В едином комплексе с калфаком смотрелся и старинный накосник ("тезмә" и "чәч-тәңкәсе") из 1-2 полос ткани, зашитый монетами, бляхами, кисточками и проч. Внешним видом он напоминал наспинную часть кашпау. В комплекте с мягким калфаком, удерживаясь завязками у основания косы, перекрываясь убором в верхней части, он смотрелся как единое целое. Позднее калфаки стали драпировать на правый бок.

Казанские татарки. Художник К.Гун. 1862 г.

Казан-татар хатын-кызлары. Рәссам К.Гун. 1862 ел.

Kazan Tatar Women. Painting by K.Gun. 1862.



Накосники – тезмә. Ткань, жетоны, бляхи.
Тезмәләр. Тукыма, жетоннар, җиз тәңкәләр.
Tezmeh hair ornament on textile base with medals and plaques.



В конце XVIII – начале XIX вв. во Франции и России очень популярными становятся кашемировые шали (Индия). Большой спрос вызвал большой их ввоз из Франции и бурный рост производства платков и шалей в России. В их декоре использовались часто восточные мотивы.

С первой половины XIX в. ситцевые, шелковые, парчевые платки и шали мануфактурного производства пополнили головные уборы татарских женщин. Покрывала подразделялись на два типа: нижние и верхние.

Нижние ("тастар", "өрпәк", "яулык") белого цвета с вышивкой надевались непосредственно на голову и плотно закрывали голову, лоб, шею. С появлением фабричных платков в начале века тастар вышел из употребления, название "яулык" было перенесено с расшитого убора на квадратный платок, способ повязывания которого (в роспуск) повторял прежнюю форму. Называли такие платки "француз яулык". На них надевали шапочку – сферическую

Головное покрывало – "өрпәк". Шелк, золотный позумент, бахрома.

Баш япмасы – өрпәк. Ефәк, алтын укалы тасма, чуклар.

Orpaek head covering of silk; gold galloon trimming and fringe.

Покрывало "өрпәк" в комплексе с шапкой "камчат бурек". Флеровая ткань, золотный позумент, капитель. Мех, бархат.

Баш япмасы "өрпәк" камчат бүрек белән берлектә. Өрфия тукыма, алтын укалы тасма, ука-җеп. Мех, бәрхет.

Orpaek head covering of crape cloth worked with gold galloon trimming and bullion with kamchat burek cap of fur and velvet.



тканевую или меховую, или закрепляли дополнительным платком, сложенным на угол, с узлом сзади. Замужние женщины, соблюдая приличия, ходили дома в нижнем покрывале; в гостях – часто не снимали верхнего.

Верхние покрывала служили для выхода из дома и были ярких расцветок. По форме они представляли вытянутый прямоугольник, надеваемый на боковую кромку или квадрат, сложенные на угол. Свободно свисая с головы, они позволяли закрыть нижнюю часть лица и фигуру. Для таких верхних покрывал служили восточные шелковые ткани или парчовые фабричные платки, иногда два неразрезанных между собой.

Женщина Казанских татар. Художник А.Мартынов. 1808 г.

Казан татарлары хатын-кызы. Рәссам А.Мартынов. 1808 ел.

A Kazan Tatar Woman. Painting by A. Martynov. 1808.

Туфелька женская. Шелк, фольга, золотная вышивка.

Хатын-кыз башмакчыгы. Ефәк, фольга, алтын җепләр белән чигеш.

Woman's silk slippers worked with foil and gold thread.






Костюмы молодой и пожилой горожанок.


Шәһәрдә яшәүче яшь һәм өлкән яшьтәге хатын-кыз костюмнары.

Costumes of young and old townswomen.






Фрагмент вышитого “орпека”. Шелк. Тамбур.
Чигүле өрпәк фрагменты. Ефәк. Тамбурлы чигеш.
Detail of silk orpaek head covering worked in chain stitch.




Головное женское верхнее покрывало. Восточный шелк с золотными нитями.
Хатын-кызның баш япмасы. Алтын җепле көнчыгыш ефәге.
Woman's outer head covering of Oriental silk with gold thread.



Ювелирные женские украшения этого времени – показатель материального достатка и общественного положения семьи. Как правило, украшения изготовлялись из серебра, сверху золотились, инкрустировались камнями. Предпочтение отдавалось коричневому сердолику и голубовато-зеленой бирюзе, наделявшейся магической силой. Часто встречались сиреневые аметисты, дымчатые топазы и горный хрусталь. У женщин из богатых семей имелся полный набор традиционных ювелирных украшений. Здесь и перстни, кольца, ношение которых связано с общемусульманской традицией; браслеты разных видов; разросшиеся до огромных размеров застежки ворота – “яка чылбыры”; накосники; нагрудная перевязь – синтез оберега и украшения и др.



Платки парчовые с восточными узорами. Подмосковные мануфактуры. Первая половина XIX в.

Шәрыкча бизәкле парча яулыклар. Мәскәү яны мануфактуралары. XIX йөзнең беренче яртысы.

Brocade headscarves with Oriental patterns. Moscow region manufactories, first half of 19th century.



Накосники – чулпы. Серебро, самоцветы. Скань, гравировка, инкрустация.

Чулпылар. Көмеш, асылташлар. Үреп-бөтереп, граверлап, инкрустациялэп эшләнгәннәр.

Chulpa hair ornament in silver filigree with engraved decoration and inlaid work; semi-precious stones.



Серьги. Серебро. Гравировка. Начало XIX в.

Алкалар. Көмеш. Гравердап ясалган. XIX йөз башы.

Ear ornaments of solid silver with engraving. Early 19th century.

Казанско-татарские украшения достигли в первой половине XIX в. апогея своего развития как по массивности и законченности, так и по изяществу, совершенству исполнения, полихромии, за счет большего использования ажурной скани и драгоценных камней.

В женском костюме украшения дополняли пластичность и цветовой эффект тканей, а кроме того создавали при движении звуковой эффект.


Зажиточные горожанки, кроме украшений, достаточно широко применяли косметику, дававшую возможность достичь идеала национальной красоты: темных блестящих бровей и волос, миндалевидных глаз сквозь опущенные пушистые ресницы, нежной кожи лица и рук, луноликости образа. Брови окрашивали усмой, ресницы – сурьмой,



Нагрудная перевязь – хэситэ. Ткань, позумент, ювелирные бляхи.
Күкрәк бәйләвече – хәситә. Тукыма, укалы тасма, ювелир җиз тәңкәләр.
Khasiteh shoulder-belt: a galloon-trimmed textile base with jewellery plaques.



Ожерелье из уральских самоцветов в оправе из серебра.
Көмеш кысадагы Урал асылташларыннан муенса.
Silver necklace set with semi-precious Urals stones.



Косметика татарских женщин.

Татар хатын-кызларының бизәнү әйберләре.

Cosmetics of Tatar women.

лицо – китайскими белилами, ввозимыми из Средней Азии и Китая. Краску для ногтей – хну – женщины изготовляли сами из растертых листьев комнатного цветка – бальзамина с добавлением квасцов. Хну привязывали к ногтям на ночь, и к утру они окрашивались в желтовато-красный цвет. Широко был распространен способ мытья волос кислым молоком – катыком, что способствовало хорошему промыванию, а также, по мнению женщин, их сохранению и росту. С Востока поступали и ароматические средства – мускус, сок душистого базилика, розовое масло.

В целом костюм этого времени, сохраняя основные компоненты традиционный одежды и общий силуэт, имеет предельно насыщенную цветовую структуру, построенную на умножении декоративных эффектов. Но



Воротниковая застежка – "яка чылбыры". Серебро, позолота. Самоцветы. Скань, инкрустация камнями.

Яка чылбыры. Көмеш, йөгертелгән алтын. Асылташлар. Үрепбөтереп, ташлар белән инкрустациялəп эшлəнгəн.

Yaka chylbyry collar pendant of silvergilt in openwork filigree, set with semi-precious stones.



Накосники – чулпы. Серебро, позолота, самоцветы. Скань, инкрустация.

Чулпылар. Көмеш, йөгертелгән алтын, асылташлар. Үреп-бөтереп, инкрустациялəп эшлəнгəн.

Chulpa hair ornaments of silvergilt in openwork filigree, set with semi-precious stones.

при всей своей цветовой экзотичности, “восточности”, он не выпадает из общей мировой тенденции моды: приталенного силуэта, отказа от больших плоскостей белого цвета, широкого использования подольного неширокого волана, украшения объемными цветами, позументами, драгоценностями.

2 БҮЛЕК

XIX ЙӨЗ БАШЫ – XIX ЙӨЗ УРТАСЫ КОСТЮМЫ

XIX йөзнең беренче яртысы – патша хөкүмәте тарафыннан Урта Азия белән сәүдә итү, промышленность үсеше максатларына юнәлдерелгән татар сәүдә капиталының көчле үсеш алган вакыты. Бу кием-салым үсеш-үзгәрешендә дә чагылыш таба. Шушы заман костюмы алдагы чорның (бигрәк тә XVIII йөзнең) өслүб бөтенлеген тулаем кабул итә, ләкин аның кайбер өлешләре үзгәрешләр кичерә.

Ир-ат киеме иясенең мал-мөлкәте күпме булуга карап киндердән яки юка тукымадан тегелгән, туникасыман киселешле, утыртма якалы ак күлмәктән торган. Шәһәр кешеләренең бәйрәм күлмәкләре кайбер очракларда чигүле кайтарма яка белән тегелгән, ләкин туры күкрәк уемы аермачык сакланган. Ике ыштан: ачык төсле юка тукымадан эчке ыштан һәм караңгырак төсләрдәге, еш кына буй-буй сызыклы чалбар киеп йөрү гадәте булган. Өскә өй киеме булып саналган җиңел камзул кигәннәр. Елның җылы вакытында урамга киеп чыга торган өс киеме булып билле казаки яки туры аркалы, еш кына эчсез җилән һәм чикмән торган. Бу чорда камзулларны, казаки һәм җиләннәрне шәрыктан кайтарылган төрле төстәге ефәк, атлас, парча тукымалардан, ә чикмәннәрне бертөрле караңгы төстәге йон тукымалардан теккәннәр.

Кышын билле калын бишмәт һәм тәнгә сыланып торган яки туры аркалы туннар кигәннәр. Җылылык өчен кышкы киемне билдән буганнар.

Киемнең тәнгә сыланып, ятып торуы гадәттәгечә бил өлешендә тукыманы арттакта һәм ян җәйләрен тарайту юлы белән барган. Өс киеменең тирән каплатмалы булуына чабуның ян җәйләренә чөйсыман ялганмалар ясау ярдәмендә ирешелгән. Бу татар киеменә билле һәм трапеция рәвешле силуэт биргән, ә мондый үзенчәлекләр моданың XIX йөзнең беренче яртысындагы европа юнәлешләренә дә туры килгән.

Ир-атлар даими киеп йөргән баш киеме – түбәтәй (такыя). Ул ярымшарны яки биек булмаган конусны хәтерләткән. Аны рәсемле ачык төстәге тукымалардан теккәннәр, бертөрле генә тукымадан тегелсә, бөтен өслеген чигү, аппликация һәм укалы тасма белән бизәгәннәр. Кышын түбәтәй өстенә ярымшар кыяфәтле тире бүрек кигәннәр. Сәүдә белән мәшгуль булган кешеләрдә каракул тиредән тегелгән, яссы түбәле, тәбәнәк цилиндр рәвешле бүрекләр күренә башлый, ләкин бу чорда алар киң таралмый.

Озынрак мех белән кырпу тотылган мондый кыяфәтле бүрекләр XVIII йөздә шулай ук сирәк, йомышлы татарлар арасында гына очраган.

